| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 сентябрь № 711

г. Казань

Урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет белем учреждениесенең исемен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет белем учреждениесенең исемен «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына ике ай эчендә урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет белем учреждениесе уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 5 март, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 18 июнь, 246 нчы; 2009 ел, 19 гыйнвар, 24 нче; 2010 ел, 27 июль, 591 нче; 2012 ел, 2 февраль, 78 нче; 2013 ел, 31 август, 622 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1006 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Афанасий Михайлович Данилов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында»

2008 ел, 22 октябрь, 763 нче карары белән расланган 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекнең 6.1 нче пунктындагы 6.1.5 нче пунктчада «урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» дәүләт белем учреждениесе» сүзләрен «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү стратегиясен раслау турында» 2010 ел, 10 февраль, 61 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 9 февраль, 93 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2018 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Стратегия тексты буенча:

«УҺББ «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» ДБУ» сүзләрен – «Лубян урман-техник көллияте» ДБҺББУ» сүзләренә, «Урман» ДБУ» сүзләрен – «Урман хуҗалыгы» ДБУ» сүзләренә, «Урманчылык» ДБУ» сүзләрен «Урманчылык» ДКУ» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекнең 2.2 бүлекчәсендәге өченче абзацта «Урман» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләрендә (алга таба – «Урман» ДБУ)» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләрендә (алга таба – «Урман хуҗалыгы» ДБУ) сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең 5.1 бүлекчәсендә:

5.1.2 нче пунктта «Чирмешән урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен «Чирмешән урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә алмаштырырга;

5.2.2 нче пунктта «Зеленодольск урманчылыгы» ДБУ» – сүзләрен «Зеленодольск урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Саба урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Саба урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Кайбыч урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен «Кайбыч урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.2 нче пунктта «Арча урманы» ДБУ» сүзләрен «Арча урман хуҗалыгы» ДБУ» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.5 нче пунктта «Саба урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Саба урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Нурлат урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Нурлат урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Аксубай урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Аксубай урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Чирмешән урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Чирмешән урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Баулы урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Баулы урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Кәләй урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Кәләй урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Алабуга урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Алабуга урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Зәй урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Зәй урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Кама урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Кама урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Кайбыч урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен – «Кайбыч урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Арча урманчылыгы» ДБУ»

сүзләрен – «Арча урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә, «Ары урманчылыгы» ДБУ» сүзләрен «Ары урманчылыгы» ДКУ» сүзләренә алмаштырырга;

5.5.2 нче пунктның алтынчы абзацында «урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» дәүләт белем учреждениесендә (алга таба – УҺББ «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» ДБУ)» сүзләрен «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесендә (алга таба – «Лубян урман-техник көллияте» ДБҺББУ)» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 28 апрель, 350 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган югары һөнәр белеме бирүче «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе.»;

әлеге карар белән расланган Югары һөнәр белеме бирүче «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт белем учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры яраштыру советы турындагы нигезләмәнең 1.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча 2009 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында» 2009 ел, 2 февраль, 63 нче карары нигезендә эшләнде.».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 30 июль, 531 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 9 июль, 478 нче, 2015 ел, 4 июнь, 406 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасының «2014-2020 елларга урманнарны саклау һәм яклау» ярдәмче программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең «Янгын-химия станцияләренең торышы һәм аларны төзү турында мәгълүматлар» бүлекчәсендә 31 нче юлның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян урман-техник көллияте» ДБҺББУ».

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр

белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 март, 128 нче; 2015 ел, 20 апрель, 269 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында 78 нче юлның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян урман-техник көллияте» ДБҺББУ»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары тулай тораклары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында 56 нчы юлның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян урман-техник көллияте» ДБҺББУ».

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Лубян аучылык хуҗалыгы территориясен, акваториясен Татарстан Республикасында аучылык объектларына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану өчен бирү турында» 2004 ел, 26 март, 140 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\711.docx